**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**19.01.2022** **№ 96**

## «2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасын раслау турында

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 7, 10 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2012-2020 елларга әйләнә-тирә мохитне саклау» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 326 номерлы карары нигезендә һәм табигать ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә координацияләнгән гамәлләр формалаштыру, шулай ук Биектау муниципаль районында табигать мохитен торгызуга, саклауга һәм яхшыртуга юнәлдерелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасын рasларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов

Кушымта

Биектау муниципаль районы Башкарма
комитетының 19.01.2022 № 96нче
карары белән расланды

# «2022-2023 елларга БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТЕН САКЛАУ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

**ЭЧТӘЛЕК:**

# I. ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

## ТӨП ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ

1. Су ресурсларын саклау
2. Һава бассейнын саклау
3. Җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерү
4. Җирлекләрне яшелләндерү, урманнардан файдалану һәм аларны саклау
5. Биологик төрлелекне саклау
6. Җир ресурсларын саклау

**«2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасының паспорты**

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | «2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасы |
| **Программаны эшләү өчен хокукый нигезләр** | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка закон актлары |
| **Программаны эшләүчеләр** | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаны башкаручылар** | - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ<br>- Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ<br>- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ<br>- «Биектау коммуналь челтәрләре» АҖ<br>- «Бөреле коммуналь челтәрләре» ҖЧЖ<br>- «Коркачык челтәрләре» ҖЧЖ<br>- Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе (ЮХИДИ)<br>- Росреестрның Биектау бүлеге<br>- Ислейтар урман хуҗалыгы<br>- Иске-Казан урман хуҗалыгы<br>- Биектау урман хуҗалыгы<br>- Район ветеринария берләшмәсе (Ветберләшмә)<br>- «Высокогорские вести» - «Биектау хәбәрләре» район газетасы<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе<br>- Мәгариф өлкәсендә республика мәгълүмат-методик белем бирү һәм контроль үзәге филиалы (РЦИМК филиалы)<br>Район белем бирү учреждениеләре (ОУ) |

| | |
|---|---|
| **Программаның төп максатлары һәм бурычлары** | Программаның төп максатлары:<br>- формалаштыру:<br>табигать ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә бердәм сәясәт, шулай ук районның табигать мохитен торгызуга, саклауга һәм яхшыртуга юнәлдерелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру;<br>- җәмгыятьтә экологик культура.<br>Программаның максатларына ирешү шарты булып түбәндәге төп бурычларны хәл итү тора:<br>- табигать ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану өчен хокукый һәм норматив-методик база системасын булдыру;<br>- әйләнә-тирә мохит мониторингын булдыру;<br>- әлеге программага кертелгән чараларны этаплап гамәлгә ашыру;<br>- халыкка гомуми экологик белем бирүне үткәрү;<br>- әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча мәгълүмат компанияләрен үткәрү; |
| **Программаны гамәлгә ашыру сроклары** | 2022-2023 еллар |
| **Программаны финанслау чыганаклары** | - Федераль бюджет<br>- Республика бюджеты<br>- Агымдагы финанслау<br>- Оешмалар акчалары<br>- Бюджеттан тыш чаралар |
| **Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре** | Халыкның яшәү тирәлеген һәм сәламәтлеген яхшырту, экологик иминлек традицияләрен саклау һәм алга таба үстерү |
| **Программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тотучы органнар** | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ |

**Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысулы белән хәл итүнең кирәклеген нигезләү**

«2022-2023 елларга Биектау муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасы районда экологик вәзгыятьне яхшыртуга юнәлтелгән. Хәзерге вакытта әйләнә-тирә мохитнең торышы уңай түгел, ул районда экологик вәзгыятьне оптимальләштерүгә юнәлдерелгән табигатьне саклау чараларын күрүне таләп итә.

Хәзерге вакытта төп экологик проблемалар булып түбәндәгеләр тора: район чигендә автотранспорт һәм сәнәгать предприятиеләре эшчәнлеге нәтиҗәсендә атмосфераның пычрануы; эчә торган суларның сыйфаты җитәрлек канәгатьләнерлек булмау; грунт суларының биеклеген күтәрү; яшелләндерү җитәрлек булмау; калдыклар күләме арту, аларны утильләштерү һәм эшкәртү зарурлыгы; халыкның сәламәтлеге канәгатьләнмәслек; хуҗасыз хайваннарның саны арту һәм башкалар. Күп кенә барлыкка килә торган проблемалар (һава, суның сыйфаты, халык сәламәтлеге һ.б.) әйләнә-тирә мохитне пычратуның нәтиҗәләре булып тора. Проблемаларны хәл итү кызыксынган күп кенә якларның: муниципаль хезмәтләрнең, табигатьне саклау оешмаларының һәм ведомстволарының, дәүләт һәм хосусый сәнәгать предприятиеләренең эшчәнлегенә, мәнфәгатьләренә һәм мөмкинлекләренә, шулай ук халыкны һәм җитәкче затларга экологик белем бирүгә, аларны тәрбияләүгә һәм агартуга бәйле.

# ТӨП ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ

| № т/б | Чараның исеме | Финанслау чыганагы | Барлыгы, мең сум | Чыгымнар, мең сум | | Көтелгән нәтиҗәлелек |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 ел | 2023 ел | |
| **1. ҺАВА БАССЕЙНЫН САКЛАУ** | | | | | | |
| 1.1 | Атмосфераны пычратучы чыганакларны газ-тузан йотучы җайланмалар белән җиһазлау, эксплуатацияләүдәге ГОУны реконструкцияләү һәм агымдагы ремонтлау | Биектау муниципаль районы предприятиеләре | - | - | - | Газ чистарту җайланмалары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру, атмосфера һавасына пычратучы матдәләр чыгаруны киметү |
| 1.2 | Тузган техник җиһазларны алыштыру һәм ресурслар саклаучы экологик чиста технологияләр кертү | Биектау муниципаль районы предприятиеләре | - | - | - | Атмосфера һавасына пычратучы матдәләр чыгаруны киметү |
| 1.3 | Атмосфераны пычрату чыганакларын җитештерү контролен оештыру (бүлеп чыгаруларның торышына микъдари-химик анализ) | Биектау муниципаль районы предприятиеләре | - | - | - | Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә норматив таләпләрне үтәү |
| 1.4 | Автотранспортны ягулыкның экологик чиста төрләренә күчерү. Автомобильләрне газ белән тәэмин итү станцияләре челтәрен киңәйтү | Район оешмалары, предприятиеләре, хуҗалыклары. Кече һәм урта бизнес предприятиеләре | - | - | - | Автотранспорт чараларының бүлеп чыгарган газларында пычраткыч матдәләр күләмен киметү |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.5 | Күпфатирлы йортлар өчен а/т шәхси стоянкалар төзү, массакүләм чаралар уздырганда һәм сәүдә урыннарын парковка урыннары белән тәэмин итү, оешма һәм учреждениеләр хезмәткәрләренең шәхси транспортын парковкалау урыннарын имин җиһазлау | ТСЖ, УК, җирле үзидарә органнары | - | - | - | Кешенең тормыш эшчәнлеге өчен уңайлы әйләнә-тирә мохит тудыру |
| 1.6 | Предприятиеләр буенча санитар-яклау зонасын (СЗЗ) оештыру проектларын эшләү һәм СЗЗ оештыру һәм төзекләндерү чараларын үтәү | Сәнәгать предприятиеләре һәм авыл хуҗалыгы формированиеләре, Арча һәм Биектау муниципаль районнарында “ТР Россия кулланучылары күзәтчелеге” филиалы | - | - | - | Зарарлы матдәләр чыгарулар һәм физик факторлар йогынтысыннан халыкны яклауны тәэмин итү |
| **2. СУ РЕСУРСЛАРЫН САКЛАУ** | | | | | | |
| 2.1. | Су чыгымнарын беренчел исәпкә алуны алып бару | «Биектау коммуналь челтәрләре» АҖ | 440 | 220 | 220 | Суны контрольсез куллануны киметү. Суның табигый экосистемаларын саклау. |
| | | «Бөреле коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ | 160 | 80 | 80 | |
| | | «Коркачык коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ | 80 | 40 | 40 | |
| 2.2. | Суүткәргечнең һәм канализациянең тузган челтәрләрен алыштыру | «Биектау коммуналь челтәрләре» АҖ | 700 | 350 | 350 | Су югалтулары киметү. Энергетика ресурслары чыгымнары киметү. Суның табигый экосистемаларын саклау. |
| | | «Бөреле коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ | 240 | 120 | 120 | |
| | | «Коркачык коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ | 200 | 100 | 100 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.4. | Чыпчык ав. биологик чистарту корылмалары төзү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | - | - | - | Су объектларының экологик системасының тотрыклылыгын арттыру |
| 2.5. | Биектау ав. Колхоз урамындагы күлләрне чистарту | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | - | - | - | Су объектларының экологик системасының тотрыклылыгын арттыру |
| 2.6 | Гидротехник корылмаларны капиталь ремонтлауга проект-техник документация әзерләү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | - | - | - | Авария ситуацияләрен булдырмау |
| 3. **ҖИТЕШТЕРҮ ҺӘМ КУЛЛАНУ КАЛДЫКЛАРЫН УТИЛЬЛӘШТЕРҮ** | | | | | | |
| 3.1. | Контейнерлар сатып алу һәм урнаштыру. | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары | 91 | 91 | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| 3.2. | Контейнер мәйданчыкларын төзү. | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары | 500 | 500 | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| 3.3. | Калдыкларны чыгару өчен махсус техника сатып алу. | «Полигон» ҖЧҖ | - | - | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| 3.4. | Каты-көнкүреш калдыкларын аерым җыю өчен контейнерлар урнаштыру | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары | 500 | 500 | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| 3.5. | Предприятиеләр, оешмалар калдыкларын үз вакытында чыгаруны контрольдә тотуны тәэмин итү | Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары | - | - | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| 3.6. | Каты-көнкүреш калдыклары Полигонында әйләнә-тирә мохит | «Полигон» ҖЧҖ | 40 | 20 | 20 | Җир ресурсларының торышын яхшырту |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | мониторингын гамәлгә ашыру | | | | | |
| 3.7. | Калдыкларны аерып җыюны оештыру | «Полигон» ҖЧҖ | 48 | 24 | 24 | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| **4. ҖИРЛЕКЛӘРНЕ ЯШЕЛЛӘНДЕРҮ, УРМАННАРДАН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ АЛАРНЫ САКЛАУ** | | | | | | |
| 4.1. | Авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә урнашкан җирлекләрне яшелләндерү һәм урманнарны саклау тәртибен билгеләү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | - | - | - | Халыкның тормыш эшчәнлеге шартларын яхшырту |
| 4.2. | Торак йортларның, биналарның, белем бирү учреждениеләрнең, авыл хуҗалыгы, мәдәният һәм спорт идарәсе санитар зоналары чикләрендә яшел утыртмалар объектларын инвентарьләштерүне оештыру һәм уздыру. | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары | - | - | - | Халыкның тормыш эшчәнлеге шартларын яхшырту |
| 4.3. | Биектау муниципаль районының агачлар утырту, паркларны, скверларны, яшел зоналарын төзекләндерү | - Ислейтар урман хуҗалыгы<br>- Иске-Казан урман хуҗалыгы<br>- Биектау урман хуҗалыгы | - | - | - | Халыкның тормыш эшчәнлеге шартларын яхшырту |
| **5. БИОЛОГИК ТӨРЛЕЛЕКНЕ САКЛАУ** | | | | | | |
| 5.1 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләре, крестьян-фермер хуҗалыклары һәм шәхси-ярдәмче хуҗалыклар эшчәнлеге зонасында әйләнә-тирә мохитнең санитар торышын | УСХһәмП, район хуҗалыклары, Биектау районы Ветберләшмәсе, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы авыл җирлекләренең | - | - | - | Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | контрольдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру | җирле үзидарә органнары | | | | |
| 5.2 | Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметүгә юнәлдерелгән аз калдыклы һәм энергияне саклаучы технологияләр кертү | Кече һәм урта бизнес предприятиеләре | - | - | - | Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау |
| 5.3 | Торак пунктлар, шәһәр яны урманнары, су объектларының яр буе полосалары, автомобиль һәм тимер юлларның яр буе полосалары, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар, халыкның ял итү урыннары территориясендә җитештерү һәм куллану калдыкларын ташлауны бетерү | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары, район предприятиеләре | - | - | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| 5.4 | Олы Битаман авылында себер язвасы үләт базларының санитар-яклау зоналарын кыскарту | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2 300 | 2 300 | - | Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау |
| **6. ҖИР РЕСУРСЛАРЫН САКЛАУ** | | | | | | |
| 6.1. | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә саклык урман утырмалары булдыру | УСХһәмП, "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ | - | - | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.2. | Буаларны, гидротехник корылмаларны конкрет милекчеләргә беркетү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ, Биектау районында Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе, УСХһәмП, "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ | - | - | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| 6.3. | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфрак тикшерүләре үткәрү. Туфракның уңдырышлылыгын исәпкә алуны оештыру. | УСХһәмП, Биектау районында Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе | - | - | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| 6.4. | Гомумтаралган файдалы казылмалар карьерларына, грунтка инвентаризация үткәрү | Биектау районында Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе, "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ | - | - | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |
| 6.5. | Соратылмаган җир өлешләрен исәпкә алу | "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" | - | - | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | МКУ, Идарә, Роскүчемсезмилек, УСХһәмП бүлеге, Биектау муниципаль районының күп функцияле үзәк | | | | |
| 6.6 | Карьерларны рекультивацияләү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | - | - | - | Җир ресурсларының торышын яхшырту |